КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 5 ноябрь г.Казань № 964

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенция рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен раслау турында» 2019 ел, 22 октябрь, 943 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенция рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен раслау турында» 2019 ел, 22 октябрь, 943 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 29 декабрь, 1305 нче; 2023 ел, 11 март, 228 нче; 2023 ел, 27 апрель, 537 нче, 2024 ел, 28 март, 195 нче, 2024 ел, 24 июнь, 452 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль бюджеттан эшсез гражданнарга һәм гражданнарның башка категорияләренә социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетына субвенция рәвешендә бирелә торган акчалардан файдалану тәртибен раслау турында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Эшсез гражданнарга һәм гражданнарның башка категорияләренә социаль түләүләрне башкару буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү методикасын раслау һәм аны Россия Федерациясе субъектлары, федераль территорияләр һәм Байконур шәһәре арасында бүлү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 951 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Карарга теркәлгән Федераль бюджеттан эшсез гражданнарга һәм гражданнарның башка категорияләренә социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетына субвенция рәвешендә бирелә торган акчалардан файдалану тәртибен расларга.»;

әлеге карар белән расланган Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенция рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Федераль бюджеттан эшсез гражданнарга һәм гражданнарның башка категорияләренә социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетына субвенция рәвешендә бирелә торган акчалардан файдалану тәртибе»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Федераль бюджеттан эшсез гражданнарга һәм гражданнарның башка категорияләренә социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетына субвенция рәвешендә бирелә торган акчалардан файдалану тәртибе (алга таба - Тәртип) эшсез гражданнарга һәм гражданнарның башка категорияләренә социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенция рәвешендә бирелә торган акчалардан файдалану механизмнарын билгели (алга таба - субвенция).»;

4 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«картлык буенча хезмәт пенсиясенә хокук бирә торган, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган яшькә җиткәнче Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениесе (алга таба - дәүләт учреждениесе) тәкъдиме буенча эшсез гражданга билгеләнә торган пенсияне түләү;»;

алтынчы абзац үз көчен югалткан дип танырга;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба - Министрлык) буйсынуындагы дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү;»;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«вакытыннан алда пенсия рәвешендә түләүләрне исәпкә алмыйча, социаль түләүләрне гамәлгә ашыру өчен почта элемтәсе хезмәтләре өчен түләү;»;

5 пунктның өченче абзацында «дәүләт учреждениеләре» сүзләрен «дәүләт учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Дәүләт учреждениесе үзләренә билгеләгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә һәм аларның счетларына акчалар кергән саен әлеге Тәртипнең 4 пунктындагы икенче, дүртенче һәм җиденче абзацларында күрсәтелгән чыгымнарны финанслауны гамәлгә ашыралар.»;

7 пунктта «дәүләт учреждениеләре» сүзләрен «дәүләт учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта «дәүләт учреждениеләре» сүзләрен «дәүләт учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга, «тәкъдим итә» сүзләрен «тапшыра» сүзенә алмаштырырга;

10 пунктта «дәүләт учреждениеләре» сүзләрен «дәүләт учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин